| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА ШУБАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ШУБАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 17» сентябрь 2019 г. №4

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары каршындагы массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү кагыйдәләрен раслау турында**

"Массакүләм мәгълүмат чаралары турында" 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 28, 48, 55 статьялары нигезендә", «Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, гражданнарның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуы, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, Шубан авыл җирлеге башлыгы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары каршында массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү Кагыйдәләрен расларга (кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының (baltasi.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмати- телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем өстемә алам.

Шубан авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Мөҗипов.